**МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

04.05.2016 № 231

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2016 елның 26 маенда теркәлде, № 3367

Пенсия белән Россия Федерациясе
Пенсия фонды тарафыннан тәэмин ителүче
хәрби хезмәткәрләргә, хәрби җыеннарга
чакырылган гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына
"Хәрби хезмәткәрләрнең акча белән тәэмин ителүе
һәм аларга аерым түләүләр бирү турында"
Федераль законның 3 статьясының 9, 10 һәм 13
өлешләре белән гамәлгә куелган ай саен түләнә торган
акчалата компенсация билгеләү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү
һәм социаль яклау министрлыгының 18.10.2012, № 851
боерыгы белән расланган административ регламентына
үзгәрешләр кертү хакында

Пенсия белән Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан тәэмин ителүче хәрби хезмәткәрләргә, хәрби җыеннарга чакырылган гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына "Хәрби хезмәткәрләрнең акча белән тәэмин ителүе һәм аларга аерым түләүләр бирү турында" Федераль законның 3 статьясының 9, 10 һәм 13 өлешләре белән гамәлгә куелган ай саен түләнә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максатларында **боерык бирәм**:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының "Пенсия белән Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан тәэмин ителүче хәрби хезмәткәрләргә, хәрби җыеннарга чакырылган гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына "Хәрби хезмәткәрләрнең акча белән тәэмин ителүе һәм аларга аерым түләүләр бирү турында" Федераль законның 3 статьясының 9, 10 һәм 13 өлешләре белән гамәлгә куелган ай саен түләнә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ

регламентын раслау хакында" 18.10.2012 ел, № 851 боерыгы белән расланган Пенсия белән Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан тәэмин ителүче хәрби хезмәткәрләргә, хәрби җыеннарга чакырылган гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына "Хәрби хезмәткәрләрнең акча белән тәэмин ителүе һәм аларга аерым түләүләр бирү турында" Федераль законның 3 статьясының 9, 10 һәм 13 өлешләре белән гамәлгә куелган ай саен түләнә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 03.04.2015 ел, № 199, 18.11.2015 ел, № 848 боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлектә:

1.2 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 4 нче пунктча белән тулыландырырга:

"4) дәүләтләр, шәһәрләр һәм территорияләр һәм сугыш хәрәкәтләре алып бару чорларының "Ветераннар турында" Федераль законга кушымта белән күздә тотылган исемлегендә күрсәтелгән дәүләтләрдә һәм территорияләрдә Россия Федерациясе гражданнары катнашында сугыш хәрәкәтләре алып барган чорларда хәрби хезмәт бурычларын үтәгәндә хәбәрсез югалган һәм закон билгеләгән тәртиптә хәбәрсез рәвештә монда юк дип танылган яки үлгән дип игълан ителгән хәрби хезмәткәрнең яки хәрби җыеннарга чакырылган гражданинның гаилә әгъзалары.";

1.2 пунктта:

алтынчы абзацны "үлгән" сүзеннән соң ", хәбәрсез югалган" дигән сүзләр белән тулыландырырга;

җиденче абзацны "үлгәннән" сүзеннән соң ", хәбәрсез рәвештә монда юк дип танылган яки үлгән дип игълан ителгән" дигән сүзләр белән тулыландырырга;

2 бүлектә:

2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып; туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору срогы | Компенсация билгеләү турында карар бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны кушып, гаризаны биргән көннән алып сигез эш көне эчендә кабул ителә, ә әлеге гариза һәм документларны почта аша җибәргәндә – Үзәк бүлеге аларны алган көннән алып сигез эш көне эчендә.<br>Тапшырылган документларны өстәмә тикшерү һәм компенсация алу өчен нигезләрне раслау зарурлыгы булганда, карар кабул итү срогы өч айга кадәр озайтылырга мөмкин, бу хакта, | Кагыйдәләрнең 8 п."; |

| | | |
|---|---|---|
| | сәбәпләрен һәм карар кабул итүнең фаразланучы срогын күрсәтеп, гариза бирүчегә язмача хәбәр ителә. Бу очракта компенсация билгеләү турында карар өстәмә тикшерү тәмамланганнан соң сигез эш көне эчендә кабул ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылмаган. | |

2.5 пунктның “Стандартка таләпләрнең эчтәлеге” графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Компенсация билгеләү турында гариза (яшәү урынын яки Россия Федерациясенең Саклык банкы оешмасында (филиалында, структур бүлекчәсендә) ачылган лицевой счет реквизитларын күрсәтеп), түбәндәгеләр нигезендәге форма буенча:

бу Регламентның 1.2 пунктындагы 1 пунктчада күрсәтелгән гражданнар өчен – бу Регламентка 1 нче кушымта;

бу Регламентның 1.2 пунктындагы 2 һәм 3 пунктчаларында күрсәтелгән гражданнар өчен – бу Регламентка 2 нче кушымта.

Дәүләт хезмәте алучыга акча күчерү өчен, опекун (химаяче) югарыда әйтелгән кредит оешмасында опекун (химаяче) ачкан номиналь счетның реквизитларын күрсәтә.

2. Шәхесне таныклаучы документ күчермәсе.

3. Опека һәм химая органының опекун (химаяче) билгеләү турындагы карары күчермәсе – опекун (химаяче) өчен.

Бу Регламентның 1.2 пунктындагы 1 пунктчада күрсәтелгән гражданнар өстәмә рәвештә тапшыралар:

хәрби хезмәт узу чорында хәрби җәрәхәт алганлыкны раслаучы документ (хәрби билет, хәрби комиссариат белешмәсе, хәрби медицина документлары, архив белешмәләре);

медицина-социаль экспертиза федераль учреждениесенең хәрби җәрәхәт аркасында инвалидлык билгеләнү фактын раслаучы белешмәсенең күчермәсе.

Бу Регламентның 1.2 пунктындагы 2 пунктчада күрсәтелгән гражданнар өстәмә рәвештә тапшыралар:

хәрби хезмәткәрнең, хәрби җыеннарга чакырылган гражданинның алар хәрби хезмәт бурычларын үтәгәндә һәлак булуын (үлемен) раслаучы документ күчермәсе, яисә хәрби табиблар комиссиясенең хәрби хезмәткәрнең яки хәрби җыеннарга чакырылган гражданинның үлеме хәрби җәрәхәт аркасында булуын раслаучы йомгаклау нәтиҗәсе күчермәсе;

гаилә әгъзаларының компенсациягә хокукын раслаучы документлар:

хәрби хезмәт бурычларын үтәгәндә һәлак булган (үлгән) яисә хәрби җәрәхәт аркасында үлгән хәрби хезмәткәр яки хәрби җыеннарга чакырылган гражданин белән туганлык мөнәсәбәтләрен раслаучы документ күчермәсе – ата-аналар өчен;

медицина-социаль экспертиза федераль учреждениесенең инвалидлык билгеләнү фактын раслаучы белешмәсенең күчермәсе – инвалидлар булып торучы һәм 50 һәм 55 яшькә җитмәгән хатыны (ире), ата-аналары (тиңдәшле рәвештә хатын-кыз һәм ир-ат) өчен;

медицина-социаль экспертиза федераль учреждениесенең бала чактан инвалидлык билгеләнү фактын раслаучы белешмәсенең күчермәсе – шул яшькә җиткәнче инвалидка әверелгән 18 яшькә җиткән балалары өчен;

мәгариф оешмасының баланың көндәлек көндезге уку формасы буенча укуын раслаучы белешмәсе (ул 18 яшькә җиткәнгә кадәр һәр уку елында бирелә) – көндәлек көндезге уку формасы буенча мәгариф оешмасында белем алучы бала өчен.

Бу Регламентның 1.2 пунктындагы 3 пунктчада күрсәтелгән гражданнар өстәмә рәвештә тапшыралар:

хәрби хезмәт узу чорында хәрби җәрәхәт алганлыкны раслаучы документ (хәрби билет, хәрби комиссариат белешмәсе, хәрби медицина документлары, архив белешмәләре);

медицина-социаль экспертиза федераль учреждениесенең хәрби җәрәхәт аркасында инвалидлык билгеләнү фактын раслаучы белешмәсенең күчермәсе;

гаилә әгъзаларының компенсациягә хокукын раслаучы документлар:

үлгән (һәлак булган): хәрби җәрәхәт аркасындагы инвалид белән туганлык мөнәсәбәтләрен раслаучы документ күчермәсе – ата-аналар өчен;

медицина-социаль экспертиза федераль учреждениесенең инвалидлык билгеләнү фактын раслаучы белешмәсенең күчермәсе – инвалидлар булып торучы һәм 50 һәм 55 яшькә җитмәгән хатыны (ире), ата-аналары (тиңдәшле рәвештә хатын-кыз һәм ир-ат) өчен;

медицина-социаль экспертиза федераль учреждениесенең бала чактан инвалидлык билгеләнү фактын раслаучы белешмәсенең күчермәсе – шул яшькә җиткәнче инвалидка әверелгән 18 яшькә җиткән балалары өчен;

мәгариф оешмасының баланың көндәлек көндезге уку формасы буенча укуын раслаучы белешмәсе (ул 18 яшькә җиткәнгә кадәр һәр уку елында бирелә) – көндәлек көндезге уку формасы буенча мәгариф оешмасында белем алучы бала өчен.

Бу Регламентның 1.2 пунктындагы 4 пунктчада күрсәтелгән гражданнар өстәмә рәвештә тапшыралар:

хәрби хезмәт бурычларын үтәгәндә хәбәрсез югалган хәрби хезмәткәрне (хәрби җыеннарга чакырылган гражданинны) хәбәрсез рәвештә монда юк дип тану яки үлгән дип игълан итү турында суд карары күчермәсе;

гаилә әгъзаларының компенсациягә хокукын раслаучы документлар:

хәрби хезмәт бурычларын үтәгәндә хәбәрсез югалган хәрби хезмәткәр яки хәрби җыеннарга чакырылган гражданин белән туганлык мөнәсәбәтләрен раслаучы документ күчермәсе – ата-аналар өчен;

медицина-социаль экспертиза федераль учреждениесенең инвалидлык билгеләнү фактын раслаучы белешмәсенең күчермәсе – инвалидлар булып торучы һәм 50 һәм 55 яшькә җитмәгән хатыны (ире), ата-аналары (тиңдәшле рәвештә хатын-кыз һәм ир-ат) өчен;

медицина-социаль экспертиза федераль учреждениесенең бала чактан инвалидлык билгеләнү фактын раслаучы белешмәсенең күчермәсе – шул яшькә җиткәнче инвалидка әверелгән 18 яшькә җиткән балалары өчен;

мәгариф оешмасының баланың көндәлек көндезге уку формасы буенча укуын раслаучы белешмәсе (ул 18 яшькә җиткәнгә кадәр һәр уку елында бирелә) – көндәлек көндезге уку формасы буенча мәгариф оешмасында белем алучы бала өчен.

Бу Регламентның 1.2 пунктындагы 1, 2, 3, 4 пунктчаларында күрсәтелгән: бер үк вакытта пенсияне Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органыннан һәм пенсияне Россия Федерациясе Оборона министрлыгының, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының, Россия Федерациясе Иминлек федераль хезмәтенең пенсия органыннан һәм башка органнардан алучы гражданнар, өстәмә рәвештә, башка орган тарафыннан компенсация түләнмәвен раслаучы документлар тапшыралар.

Алучылар тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар һәм аларның законлы вәкилләре, өстәмә рәвештә, дәүләт хезмәте алучының мәнфәгатьләреннән чыгып эш итүгә үзләренең вәкаләтләрен раслаучы документлар күчермәләрен тапшыра.

Гариза бирүче документларны һәм белешмәләрне тиешле оешмалардан ала, шул исәптән андый мөмкинлек булганда – электрон рәвештә.

Документлар күчермәләре, Россия Федерациясе законнары нигезендә расланмаган очракта, төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Үзәк бүлеге белгече тарафыннан раслана.

Гариза почта аша җибәрелгәндә, аңа кушып бирелүче документларның күчермәләре (шәхесне таныклаучы документ күчермәсеннән гайре) Россия Федерациясе законнары нигезендә расланган булырга тиеш.

Гариза бирүче документларның күчермәләрен бер нөсхәдә тапшыра.

Гариза бирүче дәүләт хезмәте алуга гариза бланкын Үзәк бүлегенә шәхсән мөрәҗәгать итеп алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон формасы Министрлыкның рәсми сайтына урнаштырылган.

Гариза һәм аңа кушып бирелүче документларны гариза бирүче кәгазьдә шәхсән үзе яисә почта аша тапшырырга (җибәрергә) мөмкин.

Гариза һәм аңа кушып бирелүче документларны гариза бирүче көчәйтелгән квалификацияләнгән электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәре аша, шул исәптән “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәре аша тапшырырга (җибәрергә) мөмкин.

2.6 пунктның “Стандартка таләпләрнең эчтәлеге” графасын түбәндәге эчтәлектәге тугызынчы һәм унынчы абзацлар белән тулыландырырга:

“Гариза бирүче тапшыруга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе бу Регламентның 2.5 пункты белән билгеләнгән.

Гариза бирүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган югарыда санап кителгән документларны таләп итү тыела.";

2.14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| "2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, гариза бирүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урынына, шул исәптән, Россия Федерациясе инвалидларны социаль яклау турындагы законнарына тәңгәл рәвештә, әлеге объектларның инвалидлар файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә, мондый хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиаль мәгълүмат урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр | Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле офис җиһазлары, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә башкарыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү урыныннан инвалидларның тоткарлыксыз файдалана алуы, шул исәптән объектларга тоткарлыксыз керүе һәм алардан чыгуы, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү урынына бару максатыннан, объект буйлап мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиаль мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урынга, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, куела"; | |

"Стандартка таләпләрнең эчтәлеге" графасының 2.15 пунктында дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлек күрсәткечләрен түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

"инвалидларга аларның хезмәт күрсәтүләрне башка затлар белән бертигез алуына комачаулаучы киртәләрне узуда ярдәм күрсәтү";

3 бүлектә:

3.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3.6. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү

Үзәк бүлеге белгече компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) кабул ителгән карар турында, дәүләт хезмәте күрсәтү хакындагы гаризада күрсәтелгән ысул (хат, телефон, смс-хәбәр, электрон почта) белән, гариза бирүчегә хәбәр итә.

Бу пункт билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланган моменттан башлап бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) кабул ителгән карар хакында гариза бирүчегә хәбәр итү.”;

3 нче кушымтадагы блок-схемада “, уңай карар кабул ителгән очракта” дигән сүзләрне төшереп калдырырга.

**Министр** **Э.Ә.Зарипова**